**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 6 февралендәге 278 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 3456 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсус хезмәт эшчәнлеге тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең оештыру-хокукый формасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, 2019 елның 27 декабрендәге 485-ФЗ номерлы «“Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында”гы федераль законга һәм “Конкуренцияне яклау турында”гы федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 27 октябрендәге 966 номерлы «2025 елның 1 гыйнварына кадәрге чорга дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрне реформалаштыру буенча Татарстан Республикасы чаралары планы турында»гы карары нигезендә, шулай ук халыкны, оешмаларны һәм предприятиеләрне җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең эшчәнлеге белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 3456 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең эшчәнлек тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «Казан шәһәренең «Ритуал» муниципаль унитар предприятиесе» сүзләрен «Казан шәһәренең «Ритуал» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең эшчәнлек тәртибенә

кушымтасында «Казан шәһәренең «Ритуал» муниципаль унитар предприятиесе» сүзләрен «Казан шәһәренең «Ритуал» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**